**5 нче сыйныф**

**Татар әдәбиятыннан тест**

**Галимҗан Ибраһимовның «Фагыйлә» хикәясе. Хикәя жанры**

**1.«Яз башы» һәм «Фагыйлә» хикәяләрендә нинди уртаклык бар?**

а) икесендә дә төп герой — бала;

ә) төп геройларның икесе дә эшләргә дә, уйнарга да ярата;

б) икесендә дә автор табигать күренешләрен бик матур итеп сурәтли.

**2. «Яз башы» хикәясендәге Салих кебек, Фагыйлә дә «иң зур бүләк алгандагы шатлык белән» әнисе янына йөгерә. Ул нәрсәгә шатлана?**

а) туйганчы җиләк ашамаганга;

ә) әнисе белән абыйсына да җиләк, бөрлегән җыйганга;

б) көннең матурлыгына.

**3. Хикәядә сүз нинди җиләк турында бара?**

а) кура җиләге, каен җиләге;

ә) каен җиләге, җир җиләге, виктория;

б) җир җиләге, каен җиләге, бөрлегән.

**4. Хикәядә ничә вакыйга сурәтләнгән?**

а) бер вакыйга;

ә) 2—3 вакыйга;

б) күп вакыйга.

**5. Бөрлегән нинди җиләк ул?**

а) урманда, урман буйларында үсә торган, кура җиләкләре төреннән булган кып-кызыл җимешле үләнчел үсемлекнең әчкелтем татлы җимеше;

ә) кура җиләге;

б) бакчада үстерелә торган каен җиләгенең эре сорты.

**6.Бөрлегән русча ничек атала?**

а) костяника;

ә) брусника;

б) ежевика.

**7. Фагыйлә үз туганнарына карата нинди мөнәсәбәттә?**

а) ул аларны яратмый;

ә) ул кайгыртучан;

б) кыз үзен генә ярата.

**8.Татар әдәбиятында хикәя жанры кайчан формалашкан?**

а) XIX гасырда;

ә) XX гасыр башында;

б) XX гасыр уртасында.

**9. XX гасыр башында татар әдәбиятын үстерүгә зур өлеш керткән язучылар?**

а) Шәриф Камал, Фатих Әмирхан, Гаяз Исхакый, Нәҗип Думави;

ә) Фаил Шәфигуллин;

б) Фәнис Яруллин, Рәмзия Габделхакова, Айгөл Әхмәтгалиева.

**Ачкыч**

1. **Б**
2. **Ә**
3. **Б**
4. **А**
5. **А**
6. **А**
7. **Ә**
8. **Ә**
9. **А**

# Бәяләү

**8-9 балл – “5”ле**

**6-7 балл – “4”ле**

**4-5 балл – “3”ле**